**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОШТАУЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2020 ел, 6 июль № 224

**Коштаулы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының « Коштаулы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Коштаулы авыл җирлеге Советының «Коштаулы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2016 елның 12 февралендәге 22 номерлы карарының «Коштаулы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә»нең 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8.3 пунктның 6 пунктчасында «мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы» сүзләрен «индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ»сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Коштаулы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Коштаулы авыл җирлеге Башлыгы,**
**Коштаулы авыл җирлеге**
**Советы Рәисе** **Х.Ф. Сабиров**